ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТРОИЦКО-УРАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422657, РТ , Рыбно-Слободский район
с.Троицкий Урай
ул. Школьная, дом 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТРОЙ-УРАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422657, ТР,Балык Бистәсе районы,
Трой-Урай авылы
Мәктәп урамы, 4 нче йорт

Тел.: (84361) 24320, факс: (84361)24320, e-mail: Tur.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**елның 16 августы** **Трой-Урай ав** **№ 8**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирләрдә үләнне, яфракларны яндыру урыннарын һәм алымнарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 200 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, « Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 2 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынг каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы, 2016 елның 20 сентябрендәге 39 номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтене "Янгынга каршы режим турында" 2012 елның 20 сентябрендәге 390 номерлы, № 947 " Росси Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» һәм Татарста Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясендә тора пунктларның янгынга каршы тотрыклылыгын арттыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлег торак пунктларының гомуми кулланылыштагы җирләрендә учак ягу, шулай ук якындагы саклан объектыннан 50 метр ераклыкта булган урыннарда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынг каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Росси Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренең 72.1 пунктында күрсәтелгән шартлард үлән, яфракларны яндыру тыела.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режи кертелгән чорда үз көчен югалтмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авы җирлегенең Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама –буе урамы,9 йорт;Гремячк авылы, Александров урамы 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларынд һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсм порталы”нда урнаштырырга.5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкт калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трой-Урай авыл җирлеге Башлыгы Сафин Р.Х